Республика Татарстан
**Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» октябрь, 2022 ел № 721

2023 елга Питрәч муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-крайны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты уставы белән Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга расларга:

- Питрәч муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;
- балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Питрәч муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында,

хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

Утверждены
постановлением руководителя исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан
от «__» _______ 20 __ № ____

**НОРМАТИВНЫЕ ЗАТРАТЫ**
**на реализацию программ в многопрофильных образовательных организациях дополнительного образования детей Пестречинского муниципального района Республики Татарстан**

| Направление программы дополнительного образования | Территориальная дислокация | Нормативные затраты, рублей в год на 1 обучающегося | | |
|---|---|---|---|---|
| | | первый год обучения | второй год обучения | третий и последующие годы обучения |
| Художественно-эстетическое | сельская местность | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультурно-спортивное | сельская местность | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техническое творчество | сельская местность | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристско-краеведческое | сельская местность | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Эколого-биологическое | сельская местность | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Военно-патриотическое | сельская местность | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социально-педагогическое | сельская местность | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социально-экономическое | сельская местность | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Естественнонаучное | сельская местность | 8 352 | 15 467 | 18 561 |